**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 21 июнь № 415

г. Казань

2015/2016 елның ягу чорында Татарстан Республикасының ягулык-энергетика һәм торак-коммуналь комплекслары оешмаларының эш йомгаклары һәм 2016/2017 елның ягу чорына әзерләнү буенча бурычлар турында

Татарстан Республикасында ягулык-энергетика һәм торак-коммуналь комплекслар оешмалары тарафыннан 2016/2017 елның ягу чорын тотрыклы уздыруга үз вакытында һәм нәтиҗәле әзерләнү максатларында һәм «Энергия саклау турында һәм энергетиканың нәтиҗәлелеген күтәрү хакында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 ел, 23 ноябрь, ФЗ-261 нче һәм «Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 ел, 27 июль, ФЗ-190 нчы федераль законнарны үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2016/2017 елның ягу чорына әзерләнү буенча республика штабын оештырырга һәм аның кушымтада күрсәтелгән составын расларга.

2. Татарстан Республикасының министрлыкларына, дәүләт комитетларына, ведомстволарына һәм ведомстволарга караган оешмаларына – түбәндәгеләрне йөкләргә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына тәкъдим итәргә:

2017 елның 5 июленә кадәр:

2015/2016 елның ягу сезонына әзерлек чорында билгеле булган бозулар анализын исәпкә алып, узган ягу чорларында иң күп ягылган вакытларда килеп чыккан һәлакәтле хәлләр анализын исәпкә алып, оешмаларны һәм муниципаль берәмлекләрне 2016/2017 елның ягу чорында (алга таба – ягу чоры) эшләүгә әзерләү буенча тереклек эшчәнлеген тәэмин итү системаларын диагностикалау, модернизацияләү, тузган һәм нормативта каралган вакытын эшләгән челтәрләрне һәм җиһазларны алыштыру, объектларны энергия ресурсларын исәпкә алу приборлары белән җиһазландыру чараларын үз эченә алган чаралар планнарын, шулай ук Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Идел буе идарәсе катнашында (алга таба – Ростехкүзәтчелегенең Идел буе идарәсе) 2016 –

2020 елларга муниципаль җылылык һәм электр белән тәэмин итү системаларын техник яңадан җиһазлау һәм төзекләндерү программаларын эшләүне һәм раслауны;

үз ведомстволары буйсынуындагы объектларны әзерләүне һәм аларның гадәттән тыш хәлләр шартларында нормаль эшләве өчен электр энергиясенең резерв чыганаклары белән җиһазландыруны тикшерүдә тотуны тәэмин итүне;

2016 елның 15 сентябренә кадәр, тереклек эшчәнлеген тәэмин итү системаларын эксплуатацияләү өчен җаваплы оешмалар белән берлектә, тереклек эшчәнлеген тәэмин итү системаларында һәлакәтләрне һәм төзексезлекләрне оператив бетерү өчен җиһазлар, материаллар һәм запас частьләр резервын булдыруны;

җылылык һәм кайнар су белән тәэмин итү системаларында планлы ремонт үткәрелүгә бәйле рәвештә, кайнар су белән тәэмин итүне туктатып тору буенча расланган графикларны үтәүгә юнәлтелгән чаралар кабул итүне;

бюджет йөкләмәләренең (булган очракта) расланган лимитларын исәпкә алып, электр, җылылык энергиясеннән һәм табигый газдан көн дә файдаланган өчен үз вакытында һәм тулысынча түләүне тәэмин итүне;

ягулык-энергетика ресурсларына түләү өчен каралган бюджет акчасыннан максатчан файдалануны исәпкә алуны һәм тикшерүдә тотуны тәэмин итүне;

файдаланылган ягулык-энергетика ресурслары өчен бурычларны, ягулык-энергетика ресурсларын кайтартучылар белән килештерелгән графиклар буенча, ягу чоры башланганга кадәр каплау буенча чараларын күрүне;

ягу чорында эшләргә әзерләнү өчен күздә тотылган акчаны тулысынча һәм үз вакытында түләүне һәм аннан максатчан файдалануны исәпкә алуны тикшерүдә тотуны тәэмин итүне;

җылылык белән тәэмин итүче һәм җылылык кулланучы оешмаларның энергия җайланмаларына хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләрне әзерләүне һәм аттестацияләүне (белемнәрен тикшерүне) оештыруны;

энергетика һәм торак-коммуналь комплекс объектлары эшендә төзексезлекләр барлыкка килгән очракта, мәгълүматны (843) 231-14-10 телефоны, (843) 231-15-55 факсы буенча Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына, (843) 297-94-59 телефоны буенча Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгына, (843) 227-46-46, 227-46-58, 227-46-59 телефоннары буенча «Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрне бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенең Кризис очракларында идарә итү үзәге»нә, (843) 231-17-77, 132-17-71 телефоннары буенча Ростехкүзәтчелегенең Идел буе идарәсенә тапшыруны;

«Татарстан Республикасының Газлаштыру, энергия саклаучы технологияләр һәм инженерлык челтәрләрен үстерү фонды» дәүләт казна учреждениесе белән берлектә, торак йортларны үзәкләштерелмәгән җылылык белән тәэмин итүгә күчерү чаралары планнарын эшләүне;

2016 елның 15 сентябренә кадәр торак йортларны үзәкләштерелмәгән җылылык белән тәэмин итүгә күчерү эшләрен тәгәлләүне.

3. Федераль бюджет акчасы исәбеннән финансланучы оешмалар

җитәкчеләренә, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе белән берлектә, ягу чоры башланганга кадәр, файдаланылган ягулык-энергетика ресурслары өчен бурычларны каплау һәм агымдагы түләүләрне тәэмин итү буенча кирәкле чаралар күрүне тәкъдим итәргә.

4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына Ростехкүзәтчелегенең Идел буе идарәсе белән берлектә:

уку-укыту процессын оештыруда, уку-укыту үзәкләрен энергия белән тәэмин итүче предприятиеләр челтәрләренә һәм энергетика җиһазларына хезмәт күрсәтүче белгечләрне өйрәтү өчен кирәкле җиһазлар һәм күрсәтмә материаллар белән җиһазландыруда булышлык күрсәтүне һәм аларны тикшерүдә тотуны тәэмин итәргә;

Россия Федерациясе Энергетика министрлыгы билгеләгән кулланучылар электр җайланмаларын, җылылык энергетика җайланмаларын, электр станцияләрен һәм челтәрләрен техник эксплуатацияләү кагыйдәләре таләпләре нигезендә энергетика җиһазларына хезмәт күрсәтүче белгечләрне өйрәтүне гамәлгә ашыра торган уку-укыту үзәкләре персоналы белемнәренә билгеләнгән вакытларда тикшерү үткәрүдә катнашырга.

5. Түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

электр, җылылык энергиясен бирү хезмәтләрен күрсәтүче электр, җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару белән шөгыльләнүче предприятиеләргә 3 – 5 елга инвестицион планнарын төзегәндә һәлакәтләр һәм технологик өзүләр анализын исәпкә алуны;

«Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыятенә һәм Татарстан Республикасында электр энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүче оешмаларга 2016 елның 20 сентябренә кадәр, электр белән тәэмин итү турындагы шартнамәләр һәм электр белән тәэмин итүнең технологик һәм һәлакәт килеп чыккан вакытка каралган бронен килештерү актлары нигезендә, законнарга таянып, кулланучыларга электр энергиясен (куәтен) җибәрүне чикләү яки вакытлыча туктатып тору графикларын эшләүне һәм Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты, «Татарстан Республикасында ягулык-энергетика ресурсларыннан рациональ файдалануны һәм аларның сыйфатын тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе, Ростехкүзәтчелегенең Идел буе идарәсе белән килештерүне;

«Генерирующая компания» ачык акционерлык җәмгыятенә, «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыятенә, «ТГК Уруссинская ГРЭС» ябык акционерлык җәмгыятенә, «ТГК-16» ачык акционерлык җәмгыятенә, җаваплылыгы чикләнгән «Түбән Кама ТЭЦ» җәмгыятенә, җаваплылыгы чикләнгән «Газпром трансгаз Казань» җәмгыятенә, Татарстан Республикасында электр һәм җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләре күрсәтүче оешмаларга:

2016 – 2020 елларга генерация, челтәр хуҗалыгы, газ белән тәэмин итү һәм газ куллану объектларында һәлакәтләр һәм аңлашылмаучанлыклар санын киметү максатларында техник диагностика, көч һәм челтәр җиһазларын, газ һәм җылылык

белән тәэмин итү челтәрләрен яңадан җиһазлау һәм яңарту программаларын әзерләүне;

жылылык электр станцияләрендә, электр һәм җылылык челтәрләрендә һәлакәт-торгызу эшләрен алып бару өчен материаллар һәм чаралар запасларын булдыруны;

2016 елның 1 октябренә кадәр, Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының «Җылылык энергиясен, җылылык чыганагын тапшырганда технологик югалтулар нормативларын, җылылык энергиясе житештергәндә ягулыкның чагыштырмача чыгымнары нормативларын, җылылык энергиясе чыганакларында ягулык запаслары нормативларын (электр һәм җылылык энергиясен катнаш эшләп чыгару режимында эшли торган җылылык энергиясе чыганакларыннан тыш), шул исәптән җылылык белән тәэмин итү өлкәсендәге бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салу максатларында билгеләү тәртибе турында» 2012 ел, 10 август, 377 нче боерыгы нигезендә резерв ягулыгы запасларын булдыруны;

2016 елның 15 ноябренә кадәр ягу чорында эшләргә әзерлек паспортларын рәсмиләштерүне;

«Газпром межрегионгаз Казань» ябык акционерлык җәмгыятенә, җаваплылыгы чикләнгән «Газпром трансгаз Казань» җәмгыяте белән берлектә:

ягу чорында ягулык-энергетика һәм торак-коммуналь комплекслар оешмаларын Татарстан Республикасында куллану өчен кирәкле күләмнәрдә газ белән гарантияле тәэмин итү эшен үткәрүне;

суытканда кулланучыларны ягулыкның резерв төрләренә күчерү графигын һәм һәлакәт вакытында газ транспортлау системасы эшендә технология режимы бозылган очракта, газ сатып алучыларга һәлакәт аркасында газ бирүне чикләү һәм аларны бирүне туктату чираты графигын эшләүне, «Татарстан Республикасында ягулык-энергетика ресурсларыннан рациональ файдалануны һәм аларның сыйфатын тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе белән килештерүне һәм Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында раслауны:

2016 елның IV кварталына – 2016 елның 15 сентябренә кадәр;

2017 елның I кварталына – 2016 елның 15 декабренә кадәр;

«Татарстан Республикасында ягулык-энергетика ресурсларыннан рациональ файдалануны һәм аларның сыйфатын тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесенә, Ростехкүзәтчелегенең Идел буе идарәсе белән берлектә 2016 елның 1 августына кадәр җылылык җитештерү чыганаклары – 2017 елга резерв ягулык хуҗалыклары һәм резерв ягулыкның норматив запаслары булу мәҗбүри Татарстан Республикасында газ кулланучылар исемлеген әзерләүне һәм аны Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгында раслауны:

Россия техник күзәтчелеге Идел буе идарәсенә:

муниципаль берәмлекләргә 2016 – 2020 елларга муниципаль җылылык һәм энергия саклау системаларын яңарту программаларын әзерләүдә булышлык күрсәтүне һәм аларны тормышка ашыруны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыруны;

халыкны һәм социаль өлкә объектларын җылылык белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы объектларны ягу чорына әзерләүне тикшерүдә тотуны законнар нигезендә көчәйтүне;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына уку-укыту процессын оештыруда, уку-укыту үзәкләрен энергия белән тәэмин итүче предприятиеләр челтәрләренә һәм энергетика җиһазларына хезмәт күрсәтүче белгечләрне өйрәтү өчен кирәкле җиһазлар һәм күрсәтмә материаллар белән җиһазландыруда булышлык күрсәтүне;

2016 елның 5 июленә кадәр Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2013 ел, 12 март, 103 нче боерыгы белән расланган Ягу чорына әзерлекне бәяләү кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) нигезендә муниципаль берәмлекләрнең ягу чорына әзерлегенә тикшерүләр үткәрү программаларын эшләүне һәм раслауны;

2016 елның 15 сентябренә кадәр энергетика комплексы объектларын ягу чорына әзерләү чаралары планнарының үтәлешен тикшерүдә тотуны тәэмин итүне;

муниципаль берәмлекләрнең әзерлеген бәяләү буенча тикшерүләр үткәргән чорда җылылык, энергия, газ белән тәэмин итүче оешмаларда һәм социаль өлкәнең әһәмиятле объектларында укыту-өйрәнүләр үткәрүне.

6. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына эшчәнлекне тәэмин итү системасы объектларын – газ кулланучыларны ягулыкның резерв төренә күчерү, шулай ук гадәттән тыш хәлләрне һәм аларның нәтиҗәләрен бетергәндә технологик бозуларны бетерү, локальләштерү һәм җылылык, энергия, ягулык һәм су белән тәэмин итүче оешмаларның, торак-коммуналь комплекс хезмәтләренең һәм башка оешмаларның үзара хезмәттәшлеге буенча өйрәнүләр үткәрү планын Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына тапшырырга һәм ай саен аны үтәү барышы турында мәгълүмат бирергә.

7. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы һәм Ростехкүзәтчелегенең Идел буе идарәсе белән берлектә, 2016 елның 10 июленә кадәр 2016 – 2020 елларга газ белән эшләүче җиһазларны, энергия, җылылык тәэмин итү системаларын капиталь төзәтү һәм алыштыру программасын эшләүне;

2017 елга, җаваплылыгы чикләнгән «Газпром трансгаз Казань» җәмгыяте, «Газпром межрегионгаз Казань» ябык акционерлык җәмгыяте белән берлектә, җирле бюджетлар акчасы исәбеннән финансланучы оешмалар өчен ягулык-энергетика ресурсларыннан файдалану лимитларын (натураль һәм кыйммәти чагылышта), законнар нигезендә, 2016 елның 1 сентябренә барлыкка килгән бурычларны исәпкә алып, бу оешмаларның нормаль эшчәнлеген тәэмин итә торган дәрәҗәдә билгеләүне;

торак-коммуналь комплекс оешмаларының һәлакәт-техник запасын билгеләнгән тәртиптә тулыландыруны тикшерүдә тотуны;

ягулык-энергетика һәм торак-коммуналь комплекслар объектларында гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгән очракларда халыкны вакытлыча урнаштыру пунктларын билгеләүне;

идарәче компанияләрнең торак-коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен халыктан акча җыю эшен нәтиҗәле оештыруны, шул исәптән торак-коммуналь хезмәтләрдән файдаланган өчен гражданнарның вакыты чыккан бурычларын каплауга юнәлдерелгән чаралар күрүне;

яңа кулланылышка кертелә торган социаль өлкә объектларын һәм торак фонды объектларын, үз вакытында җылылык бирү өчен ягу чорында эксплуатацияләүгә әзерлек паспорты белән тәэмин итү максатында, әзерләүне тикшерүдә тотуны көчәйтүне;

күпфатирлы йортлардагы төтен һәм вентиляция каналларын идарәче оешмалар, торак милекчеләре ширкәтләре, торак-төзелеш кооперативлары тарафыннан, әлеге эш төрләрен үткәрүгә лицензияләре булган махсуслаштырылган оешмаларны җәлеп итеп тикшерүен, һәм шәхси йортлардагы төтен һәм вентиляция каналларын, әлеге чараларны гамәлгә ашыру өчен җаваплылыкны җирле үзидарә органнырының тиешле вазыйфаи затларына йөкләп тикшерүне тәэмин итү буенча чаралар күрүне;

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе белән берлектә, газ ягучы җиһазларны куллануны тикшерүдә тотуны көчәйтүне, шул исәптән:

җаваплылыгы чикләнгән «Газпром трансгаз Казань» җәмгыятенә төтен һәм вентиляция каналларына тикшерүләр үткәрүдән баш тарту очраклары турында, тиешле газ җиһазларын сүндерү турындагы тәкъдимнәр белән, мәгълүмат юллауны;

ягу чоры башлану һәм тәмамлану турында кабул ителгән муниципаль хокук акты хакындагы мәгълүматны «Торак фонды мониторингы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына (алга таба – система) кертүне;

2016 елның 1 июленә кадәр, составына Ростехкүзәтчелегенең Идел буе идарәсе вәкилен һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүчеләрне кертеп, җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның ягу сезонына әзерлеген Кагыйдәләр нигезендә бәяләү буенча комиссияләр оештыруны;

2016 елның 1 июленнән башлап, атна саен үз ведомстволарына караган социаль өлкә объектларының һәм торак фонды объектларының ягу чорында эксплуатацияләүгә әзерлек паспортларын бирүнең барышы һәм аларны дөрес тутыру турында «Торак фонды мониторингы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына, «Муниципаль берәмлекләрнең ягу чоры» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына мәгълүмат кертүне;

2016 елның 1 июленнән 1 ноябренә кадәрге чорда, һәр айның 3 сенә кадәр, бу карарга теркәлгән кушымтада күрсәтелгән форма буенча ягу чорында эшләүгә әзерләнү барышы турындагы мәгълүматны гомумиләштерү һәм алга таба «Торак фонды мониторингы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасына һәм атна саен http://ozp.gosnadzor.ru адресы буенча «Муниципаль берәмлекләрнең ягу чоры» системасына кертүне;

2016 елның 5 июленә кадәр, җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның һәм җылылык энергиясеннән файдаланучыларның ягу сезонына әзерлеген бәяләүгә

тикшерү үткәрү графигын Ростехкүзәтчелегенең Идел буе идарәсе белән килештерүне;

2016 елның 15 сентябренә кадәр, энергетика комплексы объектларын, сәнәгать һәм торак-коммуналь комплекс оешмаларын ягу чорына әзерләү чаралары планнары үтәлешен тикшерүдә тотуны тәэмин итүне;

2016 елның 1 сентябренә кадәр, җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның резерв ягулыгы хуҗалыкларын эшләрлек хәлгә китерү һәм резерв ягулыгының кирәкле запасын булдыру чараларын күрүне;

2016 елның 1 сентябренә кадәр, халыкның тереклек эшчәнлеген тәэмин итү системалары объектларының өзлексез эшләвен тәэмин итү өчен коммуналь хуҗалык оешмаларының мобиль дизель-генераторларын эшләү хәленә китерү өчен чаралар күрергә;

2015 елның 15 сентябренә кадәр, күпфатирлы йортларның әзерлек паспортларын Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә күрсәтеп, Россия техник күзәтчелеге Идел буе идарәсе һәм Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан торак-коммуналь хуҗалык объектларында ачыкланган җитешсезлекләрне бетерүне тәэмин итүне;

2016 елның 1 ноябренә кадәр, Кагыйдәләр нигезендә җылылык белән тәэмин итүче оешмаларның ягу чорына әзерлеге актларын Ростехкүзәтчелекнең Идел буе идарәсенә алуны тәэмин итүне;

2016 елның 15 ноябренә кадәр, муниципаль берәмлекләрнең ягу чорына әзерлеге паспортларын алу.

8. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары белән берлектә:

социаль өлкә объектларын һәм торак фонды объектларын, шул исәптән фатирларны аерым җылыту системаларына күчерелә торганнарын, ягу чорына әзерләү чараларын ай саен финанслауны тәэмин итәргә;

социаль өлкә һәм торак фонды объектларына җылылык җибәргән чорда «кайнар линия» телефоннарын оештырырга һәм алар турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша хәбәр итәргә;

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән берлектә:

2016 елның 1 октябренә кадәр:

ягу чорында Татарстан Республикасының ягулык-энергетика һәм торак-коммуналь комплекслары оешмаларында килеп чыгу ихтималы булган һәлакәтләргә бәйле булган гадәттән тыш хәлләрне бетерү гамәлләренең оператив планына («Стужа» оператив планы), узган ягу чорлары йомгакларын исәпкә алып, төзәтмәләр кертергә;

Татарстан Республикасының ягулык-энергетика һәм торак-коммуналь комплекслары оешмаларында гадәттән тыш хәлләрне бетерүгә һәлакәт-торгызу формированиеләренең әзерлеген тикшерүләрдә катнашырга.

9. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, халыкны һәм социаль-мәдәни билгеләнештәге учреждениеләрне коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итүче җылылык-, су-, электр- һәм газ белән тәэмин итү предприятиеләре хосусыйлаштыру планына кертелгән очракта, алу шартларында аларның билгеләнешен үзгәртүне чикләүне күздә тотарга.

10. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә күпфатирлы йортларны ягу чорында эшләүгә нәтиҗәле әзерләү чараларын үтәү барышын тикшерүдә тотуны тәэмин итәргә.

11. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014/2015 елның ягу чорында Татарстан Республикасының ягулык-энергетика һәм торак-коммуналь комплекслары оешмаларының эш йомгаклары һәм 2015/2016 елның ягу чорына әзерләнү буенча бурычлар турында» 2015 ел, 8 июль, 425 нче карары үз көчен югалткан дип санарга.

12. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 21 июнь, 415 нче
карарына кушымта

Форма

**2016/2017 елның ягу чорында эшләүгә әзерләнү барышы турында мәгълүмат**

________________________________________________________

(шәһәр (район) исеме)

2016 елның «____» _____________.

| Күрсәткечләр | Юл саны | Үлчәү берәмлеге | Үлчәү берәмлекләренең гомумроссия классификаторы буенча код | Барлыгы | Әзерләнү буенча йөкләмә | Хисап чорына кышкы шартларда эшләү өчен әзерләнгән | Капиталь төзәтү, төзекләндерү, алыштыру буенча башкарылган эшләр | Йөкләмәнең үтәлеше, % |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| Татарстан Республикасында торак фонды, | 01 | мең берәмлек | 643 | | | | | |
| | 02 | мең кв. метр | 058 | | | | | |
| шул исәптән: | | | | | | | | |
| дәүләт торак фонды | 03 | мең берәмлек | 643 | | | | | |
| | 04 | мең кв. метр | 058 | | | | | |
| муниципаль | 05 | мең берәмлек | 643 | | | | | |
| | 06 | мең кв. метр | 058 | | | | | |
| шәхси | 07 | мең берәмлек | 643 | | | | | |
| | 08 | мең кв. метр | 058 | | | | | |

* ЖКХ – торак-коммуналь хуҗалык

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Барлык милек рәвешендәге казаннар бүлмәләре | 09 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Куәте, | 10 | Гкал | | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ* | 11 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Куәте, | 12 | Гкал | | | | | | |
| Барлык милек рәвешендәге җылылык челтәрләре (ике торбалы исәпләү), | 13 | км | 008 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 14 | км | 008 | | | | | |
| Барлык милек рәвешендәге тузган җылылык челтәрләре (ике торбалы исәплəү), | 15 | км | 008 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 16 | км | 008 | | | | | |
| Барлык милек рәвешендәге җылылык насос станцияләре, | 17 | берәмлек | 642 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 18 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Барлык милек рәвешендәге җылылык насос станцияләре. | 19 | берәмлек | 642 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 20 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Барлык милек рәвешендәге суалгычлар, | 21 | берәмлек | 642 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 22 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Барлык милек рәвешендәге суүткәргеч насос станцияләре. | 23 | берәмлек | 642 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 24 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Барлык милек рәвешендәге суүткәргеч чистарту корылмалары | 25 | берәмлек | 642 | | | | | |
| үткәрү мөмкинлеге, | 26 | тәүлегенә мең куб.метр | 599 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 27 | берәмлек | 642 | | | | | |
| үткәрү мөмкинлеге, | 28 | тәүлегенә мең куб.метр | 599 | | | | | |
| Барлык милек рәвешендәге суүткәргеч челтәрләр, | 29 | км | 008 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 30 | км | 008 | | | | | |
| Барлык милек рәвешендәге тузган суүткәргеч челтәрләре, | 31 | км | 008 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 32 | км | 008 | | | | | |
| Барлык милек рәвешендәге канализация насос станцияләре, | 33 | берәмлек | 642 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 34 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Барлык милек рәвешендәге канализация чистарту | 35 | берәмлек | 642 | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| корылмалары | | | | | | | | |
| үткәрү мөмкинлеге, | 36 | түләгенә мең куб.метр | 599 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 37 | берәмлек | 642 | | | | | |
| үткәрү мөмкинлеге, | 38 | түләгенә мең куб.метр | 599 | | | | | |
| Барлык милек рәвешендәге канализация челтәрләре, | 39 | км | 008 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 40 | км | 008 | | | | | |
| Барлык милек рәвешендәге тузган канализация челтәрләре, | 41 | км | 008 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 42 | км | 008 | | | | | |
| Барлык милек рәвешендәге электр челтәрләре, | 43 | км | 008 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 44 | км | 008 | | | | | |
| Барлык милек рәвешендәге тузган электр челтәрләре, | 45 | км | 008 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 46 | км | 008 | | | | | |
| Барлык милек рәвешендәге трансформатор ярдәмче станцияләре, | 47 | берәмлек | 642 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 48 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Барлык милек рәвешендәге механикалаштырылган җыештыру өчен махсус машиналар, | 49 | берәмлек | 642 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 50 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Барлык милек рәвешендәге урам-юл челтәре, | 51 | түләгенә мең куб.метр | 058 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 52 | түләгенә мең куб.метр | 058 | | | | | |
| Барлык милек рәвешендәге күпер корылмаларын (транспорт һәм җәяүлеләр өчен күперләр һәм юл үткәргечләр), торбаларны әзерләү, | 53 | берәмлек | 642 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 54 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Теләсә кайсы милек рәвешендәге транспорт һәм җәяүлеләр өчен тоннельләр әзерләү | 55 | берәмлек | 642 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 56 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Барлык милек рәвешендәге гидротехника корылмалары әзерләү, | 57 | берәмлек | 642 | | | | | |
| шул исәптән муниципаль берәмлекләрнең ТКХ | 58 | берәмлек | 642 | | | | | |
| Газүткәргечләр | 59 | км | 008 | | | | | |
| Ягулык запаслары булдыру:<br>ташкүмер | 60 | т | 168 | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| башка каты ягулык | 61 | т | 168 | | | | | |
| сыек ягулык | 62 | т | 168 | | | | | |
| җир асты газ саклагычларында газ запаслары | 63 | мең кв. метр | 114 | | | | | |
| Традицион булмаган энергия чыганаклары, шул исәптән: | 64 | берәмлек | 642 | | | | | |
| су энергия чыганагы | 65 | кВт | 214 | | | | | |
| кояш энергия чыганагы | 66 | кВт | 214 | | | | | |
| җил энергия чыганыгы | 67 | кВт | 214 | | | | | |
| термаль энергия чыганагы | 68 | кВт | 214 | | | | | |
| Муниципаль берәмлекләрнең ТКХ кышка әзерләү өчен бүлеп бирелә торган Татарстан Республикасы финанс чаралары, шулардан: | 69 | млн. сум | 385 | | | | | |
| ТКХ оешмалары һәм берәмлекләре өчен ягулык сатып алуга | 70 | млн. сум | 385 | | | | | |
| матди-техник ресурларның һәлакәт запасларын булдыру өчен | 71 | млн. сум | 385 | | | | | |
| ТКХ объектларын төзүгә | 72 | млн. сум | 385 | | | | | |
| ТКХ объектларын капиталь ремонтлауга, модернизацияләүгә | 73 | млн. сум | 385 | | | | | |
| ТКХ кышка әзерләү өчен бүлеп бирелә торган муниципаль берәмлекләр һәм ТКХ предприятиеләренең финанс чаралары, | 74 | млн. сум | 385 | | | | | |
| шулардан: ТКХ оешмалары һәм берәмлекләре өчен ягулык сатып алуга | 75 | млн. сум | 385 | | | | | |
| матди-техник ресурларның һәлакәт запасларын булдыру өчен: | 76 | млн. сум | 385 | | | | | |
| ТКХ объектларын төзүгә | 77 | млн. сум | 385 | | | | | |
| ТКХ объектларын капиталь ремонтлауга, модернизацияләүгә | 78 | млн. сум | 385 | | | | | |
| ТКХ ягу чорына әзерләү өчен федераль бюджеттан өстәмә акча | 79 | млн. сум | 385 | | | | | |
| Элек файдаланылган ягулык-энергетика ресурслары өчен ТКХ оешмаларының бурычлары, | 80 | млн. сум | 385 | | | | | |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| шул исәптән:<br>ташкүмер өчен | 81 | млн. сум | 385 | | | | | |
| сыек ягулык өчен | 82 | млн. сум | 385 | | | | | |
| газ өчен | 83 | млн. сум | 385 | | | | | |
| җылылык энергиясе өчен | 84 | млн. сум | 385 | | | | | |
| электр энергиясе өчен | 85 | млн. сум | 385 | | | | | |

Торак-коммуналь хуҗалыкның төп фондларына техник инвентарьлаштыру үткәрү
(1 июль торышына елга бер тапкыр тутырыла)

| Т/с | Күрсәткеч | Агымдагы елның 1 июленә башкарылган, % |
|---|---|---|
| 1 | Торак фонды | |
| 2 | Казаннар бүлмәләре | |
| 3 | Үзәклештерелгән җылылык пунктлары | |
| 4 | Трансформатор ярдәмче станцияләре | |
| 5 | Суүткәргеч чистарту корылмалары | |
| 6 | Канализация чистарту корылмалары | |
| 7 | Суүткәргеч насос станцияләре | |
| 8 | Канализация насос станцияләре | |
| 9 | Җылылык насос станцияләре | |
| 10 | Җылылык челтәрләре | |
| 11 | Суүткәргеч челтәрләр | |
| 12 | Канализация челтәрләре | |

| | | |
|---|---|---|
| 13 | Электр челтәрләре | |

Оешма житәкчесе

______________________________ ______________________________
(Ф.И.Ат.ис.) (имзасы)

______________________________
(форманы төзү өчен жаваплы затның вазыйфасы исеме)

(Ф.И.Ат.ис.) (имзасы)

______________________________
(элемтә өчен телефон номеры)

«___»_________20___ ел
(документны эшләү көне)

______________________________

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 21 июнь, 415 нче
карары белән расланды

**2016/2017 елның ягу чорына әзерләнү буенча
республика штабы
составы**

| | |
|---|---|
| Фәйзуллин Ирек Әнвәр улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры – штаб башлыгы |
| Фролов Алексей Михайлович | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары – штаб башлыгы урынбасары |
| Штаб әгъзалары: | |
| Абдуллин Камил Фәргать улы | «Газпром межрегионгаз Казань» ябык акционерлык җәмгыяте генераль директоры урынбасары (килешү буенча) |
| Анфимова Алла Леонидовна | Татарстан Республикасы финанс министры урынбасары |
| Волков Евгений Георгиевич | «Таткоммунэнерго» республика житештерү берләшмәсе» ачык акционерлык җәмгыяте идарәчесе (килешү буенча) |
| Газизов Марат Зөлфәт улы | «Таткоммунпромкомплект» ачык акционерлык җәмгыяте идарәчесе (килешү буенча) |
| Гыйләҗев Роберт Фәйзи улы | «Татарстан Республикасында ягулык-энергетика ресурсларын нәтиҗәле файдалануны һәм аларның сыйфатын тәэмин итү идарәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы |
| Гыймранов Рашад Кәрибулла улы | җаваплылыгы чикләнгән «Газпром трансгаз Казань» җәмгыяте баш инженеры (килешү буенча) |
| Зарипов Марат Ривгать улы | Татарстан Републикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисе |

| | |
|---|---|
| Камалова Эльвира Рафаил кызы | Татарстан Републикасы мәдәният министрының беренче урынбасары |
| Крайнов Сергей Аркадьевич | Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы |
| Лобов Александр Николаевич | Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең башкарма комитеты житәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Миңнәхмәтов Җәүдәт Мидхәт улы | «Татарстан Республикасының Газлаштыру, энергия саклаучы технологияләр һәм инженерлык челтәрләрен үстерү фонды» дәүләт казна учреждениесе директоры» |
| Нуруллин Марс Мәкъсүм улы | «Татлизинг» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры |
| Осипов Сергей Альбертович | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары |
| Петров Борис Германович | Экология, технология һәм атом күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча технология һәм экология күзәтчелеге идарәсе җитәкчесе (килешү буенча) |
| Поминов Андрей Иванович | Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрының беренче урынбасары |
| Сәйфетдинов Марат Мөхәммәтгали улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры урынбасары |
| Сибгатуллин Илдар Нурзада улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсе башлыгы |
| Салихов Фаил Фатыйх улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары идарәсенең торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт бүлеге башлыгы |
| Сөләйманов Рифнур Хәйдәр улы | «Татэнергосбыт» ачык акционерлык җәмгыяте директоры (килешү буенча) |
| Суржко Николай Владимирович | Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры урынбасары |

| | |
|---|---|
| Тарасов Вячеслав Борисович | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыру бүлеге башлыгы |
| Фәрдиев Илшат Шәех улы | «Сетевая компания» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Хаҗиев Рәүзил Мәгъсүмҗан улы | «Генерирующая компания» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Хәйруллин Абрек Хафиз улы | «Татарстан Республикасының Коммуналь предприятиеләр берлеге» төбәк тармак эш бирүчеләр берләшмәсенең директорлар советы рәисе (килешү буенча) |
| Хөсәенов Рамил Рәвгать улы | «ТГК-16» ачык акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Шаурбин Сергей Владимирович | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының оператив эшләр бүлекчәсе өлкән белгече. |